ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Урта Камышлы ав. **БОЕРЫК**

31.01.2023 № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән Исемлеге бәясенең чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы карары нигезендә Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1нче һәм 2нче кушымта нигезендә 7793,48 сум (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) күләмендә билгеләргә һәм 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2022 елның 4 мартындагы 2нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Урта Камышлы авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче В.П. Вафина

Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1нче кушымта

2023 елның 1 феврагеннән ТР Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2600,00 |
| 3 | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1500,00 |
| 4 | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3693,48 |
| | Барлыгы | 7793,48 |

Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 2нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Мәетне кәфенләү (төрү) | 1200,00 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1400,00 |
| 4 | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1500,00 |
| 5 | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3693,48 |
| | Барлыгы | 7793,48 |